КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 7 август г.Казань № 628

Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә «Казан триатлоны - 2024» спорт ярышларын уздырганда су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә «Казан триатлоны - 2024» спорт ярышларын уздырганда кешеләрнең тормыш куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ :

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2024 елның 10 августында 4.30 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр Казан шәһәре чикләрендә Казансу елгасы акваториясендә Кремль дамбасыннан алып «Миллениум» күперенә кадәр булган җирдә «Казан триатлоны - 2024» спорт ярышларын уздыру чорында аз үлчәмле судноларны, шулай ук җилкәнле, йөреп кайту, спорт судноларын, шул исәптән гидроцикларны, байдаркаларны, ишү көймәләрен куллану тыела;

әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән судноларны файдалануны тыю «Казан триатлоны - 2024» спорт ярышларын әзерләүгә һәм уздыруга җәлеп ителгән судноларга кагылмый.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына халыкка кертелә торган тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат җиткерү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә әлеге карарда билгеләнгән тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин